# Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге составына керүче Нефтебаза поселогы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
# КАРАР

24 ноябрь, 2021 ел №4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 23 нчы ноябрендә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

"Сез Бәтке авыл җирлеге территориясендә 2022 елда Нефтебаза поселогы территориясендә яшәү урыны буенча Бәтке авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булмаган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүләр кертергә һәм I һәм II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз карт гражданнар һәм күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләүне киметергә һәм әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз) сум күләмендә билгеләргә килешәсезме?, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдереләчәк:

- Нефтебаза авылында балалар мәйданчыклары һәм спорт тренажерлары сатып алу һәм урнаштыру;
- Нефтебаза поселогында тукталыш павильонын сатып алып урнаштыру .

«ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы **347** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **212** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **189** кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы **23** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бэтке авыл җирлеге Нефтебаза поселогы гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2022 елда яшәү урыны буенча Бәтке авыл җирлеге Нефтебаза поселогы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Нефтебаза авылында балалар мәйданчыклары һәм спорт тренажерлары сатып алу һәм урнаштыру

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Тукай муниципаль районы Бэтке авыл җирлеге Нефтебаза поселогы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Бэтке авыл җирлеге Нефтебаза поселогы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бэтке авыл җирлеге Башлыгы В.А.Валиева